СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«15» октябрь, 2025 ел Алабуга шәһәре № 9

## Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы 26 статьясы, Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 50 статьясы, Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 20 апрелендәге 221 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1 .Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрергә (алга таба - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе).

2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә кандидатлардан конкурска документлар кабул итү 2025 елның 18 октябреннән 2025 елның 6 ноябренә кадәр түбәндәге адрес буенча гамәлгә ашырыла: 423603, Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Нефтяниклар проспекты, 30 нчы йорт, 16 нчы кабинет. Көн саен (ял һәм бәйрәм көннәреннән тыш) 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурсны үткәрү датасын һәм вакытын: 2025 елның 12 ноябренә, 10.00 сәгатькә билгеләргә.

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә кандидатураларны карау конкурсын үткәрү урыны итеп: Татарстан

Республикасы, Алабуга шәһәре, Нефтяниклар проспекты, 30 нчы йорт адресында урнашкан Совет бинасын билгеләргә.

4. Түбәндәгеләрне расларга:

4.1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең вазифасын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссиясе составын һәм конкурс үткәрү шартларын (1 нче, 2 нче кушымталар)

4.2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссиясенең эш регламентын (3 нче кушымта).

4.3. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт формасын һәм шартларын (4 нче кушымта).

5. Әлеге карарны һәм Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү турындагы хәбәрне «Новая Кама» газетасында бастырып чыгарырга, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://городелабуга.рф/.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль корылыш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Рәис урынбасары А.В.Косов

Алабуга муниципаль районы Советының
2025 елның 15 октябрендәге
9 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссиясе составы**

1. Косов Александр Владимирович - Алабуга муниципаль районы Башлыгы урынбасары;
2. Соколова Светлана Вил кызы - Иске Күклекк авыл җирлегенең 1 нче сайлау округы депутаты, комиссия рәисе урынбасары;
3. Абдуллина Адилә Илдус кызы - 12 нче шәһәр сайлау округы депутаты, комиссия секретаре;
4. Мингалиева Рәзимә Тимерхан кызы - Илмәт авыл җирлегенең 4 нче сайлау округы депутаты; комиссия әгъзасы;
5. Гарипов Илнур Мәхмүт улы - Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе җитәкчесенең беренче урынбасары - Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы, комиссия әгъзасы;
6. Заһидуллин Рөстәм Илдус улы - Татарстан Республикасы юстиция министры, комиссия әгъзасы;
7. Җамалиев Рөстәм Рәсим улы - Татарстан Республикасы Территорияләр белән эшләү идарәсенең баш киңәшчесе, комиссия әгъзасы;
8. Шаһивәлиев Тимур Наил улы - Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Алабуга» МИЗ» ААҖ генераль директоры (килешү буенча), комиссия әгъзасы.

Алабуга муниципаль районы Советының
2025 елның 15 октябрендәге
9 номерлы карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү шартлары**

1. Конкурсны үткәрү датасы: «12» ноябрь, 2025 ел

2. Конкурсны үткәрү вакыты: 10.00 сәгатьтә.

3. Конкурсны үткәрү урыны: Алабуга муниципаль районы Советы бинасы (423603, Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Нефтяниклар проспекты, 30 нчы йорт).

3. Конкурс документларын һәм гаризаларны тапшыру урыны: 423603, Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Нефтяниклар проспекты, 30 нчы йорт, 16 нчы кабинет.

4. Өстәмә мәгълүмат өчен түбәндәге телефон буенча мөрәҗәгать итәргә мөмкин:(885557) 3-01-54. Документлар Алабуга муниципаль районы Советының оештыру бүлеге тарафыннан кабул ителә.

5. Конкурста катнашуга гаризалар, конкурс документларын кабул итү датасы һәм вакыты: «06» ноябрь, 2025 ел, 17.00 сәгатькә кадәр.

6. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасы кандидатларына квалификация таләпләре:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата:

- югары белеме булу;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата:

- кимендә ике ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә дүрт ел эш стажы;

3) һөнәри белеменә һәм күнекмәләренә карата:

Россия Федерациясе Конституциясе, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Шәхси

мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон, «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, вазифаи бурычларны үтәүгә карата башка норматив хокукый актлар, хезмәтне саклауның норматив таләпләре һәм янгынга каршы куркынычсызлык кагыйдәләренә таянып, шулай ук мәгълүмати-коммуникацион технологияләр, компьютер һәм башка оештыру техникасы, кирәкле программа тәэминаты, хезмәт мәгълүматы белән эшләү, эш алып бару һәм эшлекле аралашу нигезләре өлкәсендә белем һәм күнекмәләр булу.

Контракт буенча билгеләнүче Башкарма комитет җитәкчесе вазифасына кандидатларга өстәмә таләпләр белән кимендә биш ел идарә эшчәнлеге тәҗрибәсе булу карала.

Әлеге пунктта идарә эшчәнлеге дигәндә оешма җитәкчесе, җитәкче урынбасары, дәүләт органы, муниципаль орган вазифаларында, шулай ук аларның структур бүлекчәләре җитәкчеләренең вазифаларында эшләве дә карала.

7. Конкурста катнашырга теләүче затлар конкурс комиссиясенә гариза белән бергә түбәндәге документларны да теркәп тапшыралар:

1) Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета;

2) паспорт күчермәсе;

3) хезмәт договоры (контракты) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, нотариаль рәвештә яисә эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе;

4) белем һәм квалификация турында, шулай ук, граждан теләге буенча, өстәмә һөнәри белем турында, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү турында документларның нотариаль яисә кадрлар хезмәтләре тарафыннан таныкланган күчермәсе;

5) мәҗбүри пенсия иминияте иминият таныклыгының күчермәсе, хезмәт шартнамәсе (контракты) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;

6) Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында физик затны исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

7) запаста торучы гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле з атлар - хәрби исәпкә алу документының күчермәсе;

8) муниципаль хезмәткә керүгә комачаулый торган авыруның булмавы турында медицина оешмасы бәяләмәсе;

9) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгълүмат урнаштыру турында муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 18.1. статьясында каралган белешмәләр;

10) федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документлар.

8. Мөрәҗәгать итүче затка документларның исемлеген һәм аларны алу датасын күрсәтеп, расписка бирелә.

Тәкъдим ителгән документларны кабул итү һәм тикшерү конкурс комиссиясе секретаре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

9. Граждан конкурста катнашуга аның Башкарма комитет җитәкчесе вазифасына квалификация таләпләренә туры килмәве, шулай ук муниципаль хезмәткә керү һәм аны узу өчен муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә кертелми.

Конкурста катнашуга кертелүдән баш тарткан очракта граждан комиссия кабул иткән карарга суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

Вазифаны биләүгә конкурста катнашучы теләсә кайсы вакытта үз гаризасын кире алырга хокуклы.  Документларны вакытында һәм тулы күләмдә тапшырмау яисә рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданинны конкурста катнашуга кертүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Алабуга муниципаль районы Советының
2025 елның 15 октябрендәге
9 номерлы карарына 3 нче кушымта

**Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссиясенең эш регламенты**

## 1 бүлек.
## ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә кандидатураларны карау комиссиясе (алга таба - Конкурс комиссиясе) Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын (алга таба - вазифа) биләүгә конкурс үткәрү максатларында төзелгән һәм Алабуга муниципаль районы Башлыгы әлеге вазифага дәгъва итүче белән хезмәт контракты төзегәнче гамәлдә була.

2. Конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе тарафыннан федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килми торган дәгъвачыларның һөнәри һәм шәхес сыйфатларын бәяләү ысуллары кулланылырга мөмкин.

## 2 бүлек.
## Конкурс комиссиясе утырышларын үткәрү тәртибе

1. Конкурс комиссиясе утырышларын аның рәисе үткәрә.

2. Тапшырылган документлар нигезендә конкурс комиссиясе кандидатларны конкурста катнашуга кертү турында карар кабул итә.

Конкурс катнашучы вазифаларны биләүгә кимендә ике кандидат булганда үткәрелә.

Конкурста катнашуга бер генә кандидат гариза биргән очракта, конкурс үтмәгән дип танылa.

3. Конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, аның утырышы хокуклы дип санала.

4. Конкурс уздырганда конкурс комиссиясе кандидатларны алар тапшырган документлар нигезендә бәяли, кандидатлар белән әңгәмәләр үткәрә, шул ук вакытта аларның һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек буенча эш стажына, вазыйфаи бурычларын үтәү өчен кирәкле һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләренә туры килүе бәяләнә.

5. Конкурс комиссиясе карарлары аның утырышта катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булганда, конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч санала.

6. Конкурс комиссиясе конкурс процедураларын үткәрү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) кандидат Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасына карата квалификация таләпләренә туры килә;

2) кандидат Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасына карата квалификация таләпләренә туры килми;

3) кандидат кадрлар резервына кертүгә тәкъдим ителгән.

7. Конкурс комиссиясе карары һәм конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа утырышта катнашкан конкурс комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм әгъзалары имза сала.

8. Конкурс нәтиҗәләре һәм кандидатлар турында мәгълүмат Алабуга муниципаль районы Советына конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан тапшырыла.

9. Башкарма комитет җитәкчесен билгеләү Алабуга муниципаль районы Советы карары белән рәсмиләштерелә.

10. Район Башлыгы Башкарма комитетның билгеләнгән җитәкчесе белән контракт төзи.

11. Конкурс комиссиясе конкурста катнашкан кандидатларга конкурс нәтиҗәләре турында ул тәмамланган көннән алып 30 көн эчендә язма рәвештә хәбәр итә.

12. Конкурста катнашкан кандидатларның документлары язма гариза буенча конкурс тәмамланган көннән алып өч ел эчендә кире кайтарыла.

Әлеге вакыт узганчы документлар җирле үзидарә органнары архивында саклана, шуннан соң юк ителергә тиеш.

Алабуга муниципаль районы
Советының 2025 елның 15 октябрендәге
9 номерлы карарына 4 нче кушымта

**Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт төзү**

20___ елның «___» _____ №___

Муниципаль берәмлек башлыгы (алга таба - башлык) «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы һәм Алабуга муниципаль районы Уставы (алга таба - устав), бер яктан, һәм Алабуга муниципаль районы Советы карары белән билгеләнгән «___» ____20____ел Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (алга таба – Башкарма комитет җитәкчесе) вазифасына, икенче яктан, түбәндәгеләр турында әлеге контрактны төзеделәр.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге контракт Башкарма комитет җитәкчесе һәм җирле үзидарә органнары арасында хезмәт мөнәсәбәтләрен һәм башка мөнәсәбәтләрне җайга сала, законнар һәм устав нигезендә әлеге контракт якларының хокукларын һәм бурычларын билгели.

1.2. Законнарда, уставта һәм әлеге контрактта билгеләнгән шартларда Башкарма комитет җитәкчесе әлеге контрактның гамәлдә булу чорына Башкарма комитет җитәкчелегенә буенча үз өстенә йөкләмә ала.

## 2. Контрактның төп шартлары

2.1. Башкарма комитет җитәкчесе вазифага конкурс нәтиҗәләре буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан билгеләнә.

2.2. Башкарма комитет җитәкчесе муниципаль хезмәткәр һәм Башкарма комитетны җитәкли.

2.3. Башкарма комитет җитәкчесе үз эшчәнлегендә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы һәм район Башлыгы тарафыннан контрольдә тора һәм аларга хисап тота.

2.4. Әлеге контракт буенча эш Башкарма комитет җитәкчесе өчен төп юнәлеш булып тора.

## 3. Башкарма комитет җитәкчесенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә кагылышлы өлешендә хокуклары һәм бурычлары

3.1. Башкарма комитет җитәкчесенең хокуклары һәм бурычлары законнар, устав, башка муниципаль хокукый актлар һәм әлеге контракт белән билгеләнә.

3.2. Башкарма комитет җитәкчесе:

3.2.1. Башкарма комитет эшчәнлегенә бердәм башлангыч принципларында җитәкчелек итә һәм Башкарма комитетның үз компетенциясенә керә торган вәкаләтләрен үтәве өчен муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы һәм Башлык каршында шәхси җаваплы була;

3.2.2. Башкарма комитетны муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы, район Башлыгы, җирле үзидарәнең башка органнары, шул исәптән башка муниципаль берәмлекләр, дәүләт хакимияте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләрдә тәкъдим итә;

3.2.3. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы каравына муниципаль берәмлекнең комплекслы социаль-икътисади үсеше планнары һәм программалары проектларын һәм аларның үтәлеше турындагы хисапларны тапшыра;

3.2.4. Башкарма комитет структурасы проектын, Башкарма комитет хезмәткәрләренең иң чик санын һәм аларның хезмәтен түләү фондын раслауга кертә, хезмәткәрләрнең иң чик саны һәм хезмәткә түләү фонды белән билгеләнгән расланган структура нигезендә Башкарма комитетның штат расписаниесен раслый;

3.2.5. Район Башлыгы белән килештереп билгели һәм Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарларын вазифаларыннан азат итә, алар арасында вазифаларны бүлә, муниципаль хезмәткәрләрне һәм район Башкарма комитетының башка хезмәткәрләре вазифасына билгеләп куя һәм вазифаларыннан азат итә, аларның эшчәнлеген тикшереп тора, аларга кызыксындыру һәм дисциплинар җаваплылык чараларын куллана;

3.2.6. Расланган бюджет нигезендә муниципаль берәмлек акчалары белән эш итә, законнар нигезендә муниципаль берәмлекнең бюджет һәм башка счетларын ача һәм яба;

3.2.7. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына үз эшчәнлеге һәм Башкарма комитет эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан куелган мәсьәләләрне хәл итү турында еллык хисаплар тапшыра;

3.2.8. Халыкка Башкарма комитет эшчәнлеге турында даими хәбәр итә, Башкарма комитет хезмәткәрләре тарафыннан гражданнарны кабул итүне оештыра, гражданнарны атна саен шәхси кабул итә, гражданнарның

тәкъдимнәрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карый, алар буенча карарлар кабул итә;

3.2.9. Дәүләт һәм башка органнарда муниципаль берәмлекнең мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын күрә, Башкарма комитет исеменнән судка гариза бирә, ышанычнамәләр тапшыра;

3.2.10. Законнар, Устав, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарлары һәм әлеге контракт нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

3.3. Башкарма комитет җитәкчесе муниципаль берәмлек исеменнән мөлкәти һәм башка хокуклар һәм бурычлар алырга һәм гамәлгә ашырырга, ышанычнамәсез судта чыгыш ясарга хокуклы.

3.4. Башкарма комитет җитәкчесе федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, муниципаль берәмлек вәкиллекле органының уставында, норматив хокукый актларында билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча һәм җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча башкарма комитетның карарларын, шулай ук Башкарма комитетның эшен оештыру мәсьәләләре буенча күрсәтмәләр чыгара.

3.5. Башкарма комитет җитәкчесе түбәндәгеләргә бурычлы:

3.5.1. Россия Федерациясе Конституциясен, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларын, Уставны үтәргә һәм башка муниципаль хокукый актлар, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы һәм Башлыгы карарларын үтәргә һәм аларның үтәлешен тәэмин итәргә.

3.5.2. Гражданнарның һәм оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне һәм яклауны тәэмин итәргә;

3.6.3. Муниципаль берәмлек Башлыгы, вәкиллекле органы, җирле үзидарәнең башка органнары белән законнарда, уставта, башка муниципаль хокукый актларда һәм әлеге контрактта билгеләнгән тәртиптә һәм рәвешләрдә үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашырырга;

3.5.4. Үз вазифаи бурычларын намус белән башкарырга;

3.5.5. Үз хезмәт бурычларын үтәү өчен кирәкле квалификация дәрәҗәсен саклап калырга;

3.5.6. Дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрне, шулай ук үз вәкаләтләрен үтәүгә бәйле рәвештә аңа мәгълүм булган белешмәләрне, шул исәптән гражданнарның шәхси тормышына һәм сәламәтлегенә кагылышлы яисә аларның намусына һәм абруена кагылышлы белешмәләрне фаш итмәскә;

3.5.7. Законнар нигезендә муниципаль хезмәткә бәйле чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә;

3.5.8 Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында законнарда каралган белешмәләрне, шулай ук үз иренең

(иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) тапшырырга;

3.5.9. Дәүләт һәм муниципаль милекне, шул исәптән аңа вәкаләтләрне башкару өчен бирелгән милекне сакларга.

3.5.10. Яллаучының (эш бирүченең) вәкиленә, яллаучының (эш бирүченең) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш, 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетадагы мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итәргә (алга таба - анкетадагы мәгълүматлар).

3.6. Үз вәкаләтләрен башкарганда Башкарма комитет җитәкчесе мәнфәгатьләр низагы килеп чыгу очракларын булдырмаска тиеш.

Мәнфәгатьләр конфликты дигәндә, Башкарма комитет җитәкчесенең шәхси кызыксынуы (турыдан-туры яки читләтеп) аның вазифаи (хезмәт) бурычларын (вәкаләтләрне гамәлгә ашыру) объектив үтәвенә йогынты ясый яисә йогынты ясарга мөмкин.

Шәхси кызыксынучанлыгы дигәндә, Башкарма комитет җитәкчесенең вазифаи бурычларын үтәгәндә акчалата яки әйберләтә керемнәр алу (нигезсез баю), турыдан-туры Башкарма комитет җитәкчесе, аның гаилә әгъзалары һәм аның белән туганлыкта яисә әшнәлектә торучы башка затлар (ата-аналар, ир яки хатын, балалар, ага-энеләр, апа-сеңелләр, шулай ук ир яки хатынның агаэнеләре, апа-сеңелләре, ата-аналары һәм балалары) өчен, шулай ук Башкарма комитет җитәкчесеннән финанс яисә башка йөкләмәләр буенча бәйле гражданнар яки оешмалар өчен матди яктан файдалы керемнәр алу мөмкинлеге дип аңларга кирәк.

Башкарма комитет җитәкчесе Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә яллаучының (эш бирүченең) вәкиле билгеләгән тәртиптә барлыкка килгән мәнфәгатьләр конфликты турында яисә, аңа бу хакта билгеле булуга ук, аның килеп чыгу мөмкинлеге турында хәбәр итәргә һәм мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу буенча чаралар күрергә тиеш.

3.7. Башкарма комитет җитәкчесе, укытучылар, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлегеннән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә хокуклы түгел. Бу очракта, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүе яки Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, укыту эшчәнлеге, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек чит дәүләт, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына финанслана алмый. Башкарма комитет җитәкчесе, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, Попечительләр яисә күзәтчелек советлары, чит ил коммерциягә карамаган хөкүмәтнеке булмаган оешмаларының һәм Россия Федерациясе территориясендә эш итүче аларның структур бүлекчәләренең башка органнары составына керергә хокукы түгел.

3.8. Башкарма комитет җитәкчесе законнарда, Уставта, башка муниципаль хокукый актларда, әлеге контрактта билгеләнгән башка бурычларны үтәргә тиеш.

3.9. Башкарма комитет җитәкчесе үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрендә эш итәргә, үз хокукларын гамәлгә ашырырга һәм үз вазифаларын намус белән һәм акыллы башкарырга тиеш.

## 4. Федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлешендә Башкарма комитет җитәкчесенең хокуклары һәм бурычлары

4.1. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарганда Башкарма комитет җитәкчесе түбәндәгеләргә хокуклы:

4.1.1. Федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән нигезләмәләрне, шулай ук федераль башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актлар, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очракларда, әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча карарлар, шулай ук Башкарма комитет эшен оештыру мәсьәләләре буенча күрсәтмәләр чыгарырга, аның үтәлеше аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәк булган башкарма комитет эшен оештыру мәсьәләләре буенча күрсәтмәләр чыгарырга;

4.1.2. Федераль башкарма хакимият органнарыннан, аларның территориаль органнарыннан җирле үзидарә органнарына федераль законнар белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

4.1.3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

4.1.4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе турында, шулай ук аларны тиешле матди ресурслар һәм финанс чаралары белән үтәүне тәэмин итү турында тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә;

4.1.5. Уставта каралган очракларда һәм тәртиптә үзләренә тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен вәкиллекле органга үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан өстәмә файдалану турында тәкъдимнәр кертергә;

4.1.6. Аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча законнар таләпләрен бозуларны бетерү турында вәкаләтле дәүләт органнары күрсәтмәсенә суд тәртибендә шикаять белдерергә;

4.1.7. Федераль законнар яисә Татарстан Республикасы законнары нигезендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирүне күздә тоткан башка хокуклардан файдаланырга.

4.2. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарганда башкарма комитет җитәкчесе түбәндәгеләргә бурычлы:

4.2.1 Башкарма комитетның аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле эшен оештырырга;

4.2.2. Уставта каралган очракларда һәм тәртиптә җирле үзидарә органнары тарафыннан әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен өстәмә файдаланыла торган матди ресурсларның һәм финанс чараларының һәм аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән финанс чараларының, шулай ук үз матди ресурсларының һәм финанс чараларының сакланышын һәм максатчан файдалануын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны үз вәкаләтләре чикләрендә кабул итәргә;

4.2.3. Россия Федерациясенең вәкаләтле дәүләт органнарына һәм (яисә) Татарстан Республикасының вәкаләтле дәүләт органнарына федераль законнарда һәм җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләре тапшырылган Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән нигезләмәләр нигезендә һәм үтәү йөзеннән чыгарылган муниципаль хокукый актлар турында белешмәләр бирергә;

4.2.4. Җирле үзидарә органнарына әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында хисап бирелүче федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясенең вәкаләтле дәүләт органнарына тапшырырга;

4.2.5. Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнарына әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында аерым дәүләт вәкаләтләре тапшырылган вәкаләтле дәүләт органнарына әлеге вәкаләтләрне башкару турында хисап бирергә;

4.2.6. Федераль законнар белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп торганда Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарына ярдәм күрсәтергә;

4.2.7. Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп торганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына ярдәм күрсәтергә;

4.2.8. Үз вәкаләтләре чикләрендә Россия Федерациясенең вәкаләтле дәүләт органнарының язма күрсәтмәләрендә күрсәтелгән чараларны җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарәнең вазифаи затлары тарафыннан федераль законнар белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча федераль законнар таләпләрен бозуларны бетерүгә юнәлдерелгән чаралар күрергә;

4.2.9. Үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы дәүләт органнарының язма күрсәтмәләрендә күрсәтелгән Татарстан Республикасы законнарын җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарәнең вазифаи затлары

тарафыннан Татарстан Республикасы законнарында җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнары таләпләрен бозуларны бетерүгә юнәлдерелгән чаралар күрергә;

4.2.10. Вәкаләтле дәүләт органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга таләп ителә торган финанс чыгымнарын исәпләүне тапшырырга;

4.2.11. Федераль законнарда һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату турында Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән срокларда матди ресурсларны һәм файдаланылмаган финанс чараларын кире кайтарырга;

4.2.12. Җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләре тапшырылган шартлар туганда һәм федераль законнарда яисә Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнары тарафыннан аларны гамәлгә ашыруны туктатуга юнәлдерелгән чаралар күрергә.

## 5. Район Башлыгының хокуклары һәм бурычлары

5.1. Район Башлыгы түбәндәгеләргә хокуклы:

5.1.1. Үз бурычларын үтәгәндә Башкарма комитет җитәкчесеннән Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, федераль законнарны, Татарстан Республикасы законнарын, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларын, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы һәм район Башлыгы уставын, карарларын үтәлешен таләп итәргә;

5.1.2. Үз вәкаләтләре чикләрендә Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш булган йөкләмәләр бирергә;

5.1.3. Башкарма комитет җитәкчесеннән район Башлыгы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле бәяләмәләрне, документларны, белешмә һәм башка мәгълүматны, шул исәптән соратып алына торган яисә килештерелгән вакытка тапшырылырга тиешле Башкарма комитет эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә, соратып алырга;

5.1.4 Башкарма комитет җитәкчесенә законнар һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә бүләкләү чараларын кулланырга;

5.1.5. Башкарма комитет җитәкчесен законнар нигезендә хезмәт бурычларын үтәмәгән һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен дисциплинар җаваплылыкка тартырга;

5.1.6. Башкарма комитет җитәкчесенең әлеге контрактның Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә кагылышлы өлешендә әлеге контрактның шартларын вакытыннан алда өзү турында судка мөрәҗәгать итәргә.

5.2. Район Башлыгы Башкарма комитет җитәкчесенең законнарда, муниципаль хокукый актларда һәм әлеге контрактта каралган хокукларын һәм гарантияләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү чараларын күрергә.

5.3. Федераль законнар һәм башка норматив хокукый актлар белән вәкаләт бирелгән органнар һәм вазифаи затлар таләпләре буенча һәм законнарда каралган башка очракларда вазифаи бурычларны үтәү өчен медицина бәяләмәсе нигезендә каршы күрсәтмәләр ачыкланганда, район Башлыгы Башкарма комитет җитәкчесен биләгән вазифасыннан читләштерергә (вазифаи бурычларны үтәүгә кертмәскә) тиеш.

5.4. Район Башлыгының Башкарма комитет җитәкчесе һәм башкарма комитет органнары белән үзара хезмәттәшлеге буенча башка вәкаләтләре законнар, устав һәм башка муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

## 6. Башкарма комитет җитәкчесенең эш вакыты һәм хезмәт өчен түләү

6.1. Башкарма комитет ьитәкчесенә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының гамәлдәге законнар һәм норматив хокукый актлары нигезендә акчалата түләү түләнә.

6.2. Башкарма комитет җитәкчесенә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы раслаган штат расписаниесе нигезендә вазифаи оклад билгеләнә.

6.3. Башкарма комитет ьитәкчесенә командировка чыгымнары түләнә, башка түләүләр башкарыла, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр өчен район Башлыгы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының законнарда һәм норматив хокукый актларында билгеләнгән еллык түләүле отпуск һәм башка гарантияләр бирелә.

6.4. Башкарма комитет җитәкчесе үз эшчәнлеген норматив булмаган хезмәт көне шартларында гамәлгә ашыра.

## 7. Башкарма комитет җитәкчесенең вәкаләтләре вакыты (чоры)

7.1. Башкарма комитет җитәкчесе әлеге контракт төзелгән көннән үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга керешә.

Әлеге контракт Башкарма комитет җитәкчесе вазифасына билгеләү турында карар кабул иткән (яңа чакырылыш муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы эшли башлаган көнгә кадәр) вәкаләтләре вакытына төзелә һәм ____________ел тәшкил итә.

7.2. Башкарма комитет җитәкчесенең вәкаләтләре түбәндәге очракта вакытыннан алда туктатыла:

1) үлем;

2) үз теләге белән отставкалар;

3) әлеге контрактның 9.2 яисә 9.3 билгеләнгән тәртип нигезендә контрактны өзелүе;

4) вазифасыннан ваз кичү;

5) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылу;

6) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылса яисә вафат дип игълан ителсә;

7) аңа карата судның гаепләү карары закон көченә керүе;

8) Россия Федерациясеннән читкә даими яшәү урынына чыгу;

9) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату яисә чит ил дәүләтенең гражданлыгы (подданствосы) йә яшәүгә рөхсәт кәгазе яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ булу;

10) хәрби хезмәткә чакыру яисә аны алыштыра торган альтернатив граждан хезмәтенә юллама;

11) «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 33-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 6 һәм 7 өлешләре нигезендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору;

12) Муниципаль берәмлек чикләрен яисә шәһәр округы белән җирлекне берләштерүне үзгәртү нәтиҗәсендә килеп чыккан 25 проценттан күбрәккә муниципаль берәмлек сайлаучылары санын арттыру;

13) Җирле администрация башлыгы вәкаләтләрен башкаручы муниципаль берәмлек Башлыгы вазифасына керешү;

14) Җирле администрация башлыгы вәкаләтләрен башкаручы муниципаль берәмлек Башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;

15) Халыкның турыдан-туры ихтыяр белдерүе юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле муниципаль хокукый актны бастырып чыгару срогын бозу;

16) Чит ил агенты статусы алу.

7.3. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре чоры тәмамлангач йә аның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылгач, Башкарма комитет җитәкчесе билгеләнгән тәртиптә Башкарма комитетның яңа җитәкчесен билгеләнгәнгә кадәр һәм аның белән контракт төзелгәнче үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны дәвам итә.

## 8. Якларның җаваплылыгы

8.1. Әлеге контрактның шартларын үтәмәгән һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен яклар гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы булалар.

8.2. Башкарма комитет җитәкчесе муниципаль берәмлеккә, Башкарма комитетка аның гаебе белән китерелгән зыян өчен тулы матди җаваплылык тота. Әлеге җаваплылык тиешле суд карары нигезендә йөкләнә.

8.3. Башкарма комитет җитәкчесе федераль законнар нигезендә җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкармаган яисә тиешенчә гамәлгә ашырмаган өчен шушы максатларга бүлеп бирелгән муниципаль берәмлеккә матди ресурслар һәм финанс чаралары чикләрендә федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җаваплы була.

8.4. Район Башлыгы мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу чорында башкарма комитет җитәкчесен биләгән вазыйфасыннан читләштерергә (вазыйфаи бурычларын үтәүгә кертмәскә) хокуклы. Шул ук вакытта Башкарма комитет җитәкчесенә биләгән вазифасыннан читләштерүнең барлык вакытына акчалата түләү саклана.

## 9. Контрактны үзгәртү һәм өзү. Бәхәсләрне хәл итү.

9.1. Һәр як та, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән расланганнан соң, контрактка кушымта итеп бирелә торган өстәмә килешү белән рәсмиләштерелә торган әлеге контрактны үзгәртү (төгәлләштерү) яисә өстәү турындагы мәсьәләне икенче як алдына куярга хокуклы.

9.2. Башкарма комитет җитәкчесе белән килешү яклар килешүе буенча вакытыннан алда яисә суд тәртибендә гариза нигезендә өзелергә мөмкин:

1) Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан җибәрелгән хокук бозуларга бәйле рәвештә, халыкның тормыш эшчәнлеген турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итүгә кагылышлы өлештә, шулай ук коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәүгә бәйле рәвештә азат ителергә мөмкин;

2) Татарстан Республикасы Рәисе (Татарстан Республикасы Премьер-министры) - Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлешендә җибәрелгән хокук бозуларга бәйле рәвештә, шулай ук коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны рәвештә азат ителергә мөмкин;

3) Башкарма комитет җитәкчесе - җирле үзидарә органнары һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары контракты шартлары бозылуга бәйле рәвештә.

9.3. «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазифаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәр)

булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Башкарма комитет җитәкчесе белән контракт коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы башлыгының (Рәис) гаризасы нигезендә суд тәртибендә өзелергә мөмкин.

9.4. Якларның ризалыгын күздә тоткан очракларда контрактны вакытыннан алда өзү турындагы тәкъдим башка якка контрактны туктатуның күздә тотыла торган срогына кадәр ике айдан да соңга калмыйча җибәрелергә тиеш.

9.5.Башкарма комитет җитәкчесе вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, вәкиллекле орган тарафыннан башкарма комитетның яңа җитәкчесен билгеләү турында карар кабул ителгәнчегә кадәр, аның вазифаларын район Башлыгы билгеләгән зат башкара. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы чираттагы утырышта Башкарма комитет җитәкчесе вакантлы вазифасын биләүгә конкурс игълан итү турында карар кабул итә.

9.6. Яклар арасындагы бәхәсләр гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

## 10. Контрактның гамәлдә булу вакыты

10.1. Әлеге контракт әлеге контрактның 8.1 пункты нигезендә башкарма комитет җитәкчесенең вәкаләтләре чоры тәмамланганнан соң Башкарма комитетның яңа җитәкчесе билгеләнгән тәртиптә билгеләнгәнче һәм аның белән контракт төзелгәнче гамәлдә була.

Яңа җитәкче белән контракт төзелгән көннән әлеге контрактның гамәлдә булуы туктатыла һәм башкарма комитет җитәкчелеге буенча вәкаләтләр башкарма комитетның яңа җитәкчесенә күчә.

10.2. Башкарма комитет җитәкчесе белән аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлешендә ракт аның вәкаләтләре чоры дәвамында гамәлдә була, әмма, әгәр әлеге вәкаләтләр билгеле бер срокка ия булса, аерым дәүләт вәкаләтләренең гамәлдә булу срогы дәвамында гамәлдә була.

10.3. Әлеге контрактның гамәлдә булуы законнар һәм әлеге контрактның 9 бүлеге нигезендә Башкарма комитет җитәкчесенең вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән вакытыннан алда туктатыла.

## 11. Йомгаклау нигезләмәләре

11.1. Әлеге контракт яклар имзалаган көннән үз көченә керә.

11.2. Вәкаләтләр срогы тәмамлангач яисә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылгач, Башкарма комитет җитәкчесе үз эшендә булган барлык мөһерләрне,

штампларны, финанс һәм башка документларны, яңа билгеләнгән башкарма комитет җитәкчесенә йә аның вазифаларын вакытлыча башкаручы затка кабул итү-тапшыру акты буенча тапшырырга тиеш.

11.3. Әлеге контракт бер үк юридик көчкә ия өч нөсхәдә төзелде, алар саклана: бер нөсхә - Башкарма комитетның кадрлар хезмәтендә (Башкарма комитет җитәкчесенең шәхси эшендә), бер нөсхә - район Башлыгында, бер нөсхә - Башкарма комитет җитәкчесендә.

**Якларның имзалары һәм реквизитлары:**

| | |
|---|---|
| Алабуга муниципаль районы Башлыгы | Башкарма комитет җитәкчесе |
| Фамилиясе, исеме, атасының исеме<br>_____________(имза) | Фамилиясе, исеме, атасының исеме<br>_________(имза) |

Мөһер урыны